РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

« 21» сентябрь 2015 ел Олы Кайбыч ав. № 4

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфасын биләүгә конкурс
игълан итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 46 статьясы нигезендә, Кайбыч муниципаль район Советының вәкаләтләре вакыты тәмамлануга бәйле рәвештә Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре туктатылу сәбәпле, Кайбыч муниципаль район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъвалаучылардан конкурска документлар кабул итүне 2015 елның 26 сентябреннән 2015 елның 15 октябренә кадәр Кояшлы Бульвар, 2 нче йорт, 7 нче бүлмә адресы буенча («АК БАРС» БАНК ГАҖ бинасы) шимбә һәм якшәмбе көннәреннән кала, көн саен 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр башкарырга мөмкин, тел. 2-15-34.

2. Конкурс комиссиясенә 2015 елның 16 октябрендә сәгать 10да «АК БАРС БАНК ГАҖ» бинасында (Кояшлы Бульвар, 2 нче йорт, 7 нче бүлмә) «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2015 елның 21 августындагы 291 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә туры китереп конкурс үткәрергә һәм конкурс нәтиҗәләрен һәм кандидатлар турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советына тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына кандидатураларын карау өчен конкурс комиссиясенең 6 кешедән торган составын расларга.

4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен, кушымта нигезендә 3 кеше санында конкурс комиссиясе составының яртысын расларга.

5. Әлеге карарны 2015 елның 25 сентябрендә «Кайбыч таңнары» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль
районы Башлыгы
А.И. Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Советының
2015 е. 21 сентябрендәге
4 номерлы карарына кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ ВАЗЫЙФАСЫНА КАНДИДАТУРАЛАРЫН КАРАУ ӨЧЕН КОНКУРС КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫНЫҢ ЯРТЫСЫ

1. Басыйров Рифкать Нурулла улы– «Ак Барс Кайбыч» ҖЧҖ 2 нче филиалы директоры, Ульянково авыл җирлегеннән депутат.
2. Лазарев Сергей Владимирович – «Рус Бәрлебашы төп гомуми белем мәктәбе» МБГББУ директоры, Ябалак авыл җирлегеннән депутат.
3. Сөнгатуллина Луиза Мәгыйс кызы – «Татмедиа» ҖЧҖ «Кайбыч таңнары»редакциясе газетасы баш мөхәррире.